ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылы торак пунктында
2025елда үзара салым керту турында

2025 елның 12 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештырунның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Каташ-Каран авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Каташ-Каран торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (яктылык диодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру);

2) Каташ –Каран мәдәният йорты өчен лак-буяу материаллары сатып алу, (эшләр өчен шартнамә буенча түләү);

3) Каташ - Каран авылында юлларны кардан чистарту (махсус техниканы арендалау, эшләр өчен килешү буенча түләү).

4) Каташ-Каран торак пунктында ташландык территорияләрне, көтүлекләрне чаптыру (хезмәт өчен шартнамә буенча түләү)

5) МТЗ-82 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт өчен килешү буенча түләү).

6) Каташ-Каран зираты территориясендә биек агачларны кисү (килешү буенча түләү); ташу, чистарту. (эш өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева